**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 185-33 «17» июль 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында»гы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

Азнакай шәһәре Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының дүртенче чакырылыш 2023 елның 14 декабрендәге 161-26 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында»гы Нигезләмәгә (28.05.2024 № 182-32, 01.02.2024 № 167-28 карарлар редакциясендә), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 7.1 п. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турында карарлар Башкарма комитетының муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) нигезендә кабул ителә»;

- 7.2 п. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарда түбәндәге белешмәләр булырга тиеш: - муниципаль мөлкәтнең исеме һәм аны индивидуальләштерергә мөмкинлек бирә торган башка белешмәләр (мөлкәт характеристикасы); - муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру ысулы; - мөлкәтнең башлангыч бәясе; - түләүне кичектереп тору вакыты (ул бирелгән очракта); - муниципаль мөлкәтне бәяләү нәтиҗәләре; - муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру өчен кирәкле башка белешмәләр. Унитар предприятиенең мөлкәт комплексын хосусыйлаштырган очракта, муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карар белән шулай ук түбәндәгеләр раслана: унитар предприятиенең мөлкәт комплексы составы; унитар предприятиенең мөлкәт комплексы составында хосусыйлаштырылырга тиешле объектлар (шул исәптән махсус хокуклар) исемлеге; унитар предприятиене үзгәртеп кору юлы белән төзелә торган акционер җәмгыятьнең яисә җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталы күләме; акционер җәмгыяте акцияләренең саны, категориясе һәм номиналь бәясе яисә муниципаль район өлешенең номиналь бәясе. Электр челтәре хуҗалыгы объектларын, җылылык энергиясе чыганакларын, җылылык челтәрләрен, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларын һәм мондый системаларның аерым объектларын хосусыйлаштырган очракта, «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында»гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 30.1 статьясы нигезендә

рәсмиләштерелгән инвестиция һәм эксплуатация йөкләмәләре шартлары кертелергә тиеш. Унитар предприятиенең мөлкәт комплексы составында хосусыйлаштырылырга тиеш булмаган объектлар (шул исәптән аерым хокуклар) Башкарма комитет тарафыннан алына. Муниципаль предприятие акционерлык җәмгыятенә үзгәртелгән очракта Башкарма комитет мондый предприятиене хосусыйлаштыру планын төзү турында карар кабул итәргә мөмкин. Хосусыйлаштыру планы формасы Башкарма комитет тарафыннан раслана ".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин